СОВЕТ ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

01.04.2026 с.Ямбулатово № 8 – 37

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

"Коррупциягә каршы көрәш турында" 25.12.2008 елгы 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

1.1. "Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары турында белешмәләр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында" Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Советының 07.03.2023 ел № 30-164 карары;

1.2. Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында" Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Советының 09.06.2023 ел № 69-300 карары;

1.3. "Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында төгәл булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чаралары күрү тәртибен раслау хакында" Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Советының 07.03.2020 ел № 30-162карары;

1.4. «Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Ямбулат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы

нигезләмәне раслау хакында» Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Советының 08.09.2017 ел № 29-119 карары.

2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Ямбулат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Председательлек итү,
Югары Ослан муниципаль районының
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы М.А.Жестков